КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 декабрь г.Казань № 1725

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү максатларында авиация хезмәтләрен сатып алуларны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 19 апрель, 312 нче карары белән расланган Медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү максатларында авиация хезмәтләрен сатып алуларны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү максатларында авиация хезмәтләрен сатып алуларны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 19 апрель, 312 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 17 март, 142 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү максатларында авиация хезмәтләрен сатып

алуларны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 һәм 4 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән акча Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар (алга таба шул ук эзлеклелектә – Фонд, бюджетара трансфертлар) бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына бирелә .

4. Акча белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы.

Акча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счет аша тотыла.

Бюджетара трансферт акчасы Фонд тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган шәхси счет аша тотыла.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан финанслауның иң чик күләмнәрен җиткергәннән соң расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җиткерә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы агымдагы айның 20сенә кадәр бюджетара трансфертларны Фондның бюджет заявкалары нигезендә Фонд бюджетына тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре, расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан җиткерелгән иң чик финанслау күләмнәре чикләрендә бирә.»;

7 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидияне файдалану нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү һәм аларга ирешү өчен кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап – субсидия алынган елдан соң килә торган елның 10 гыйнварыннан да соңга калмыйча.».

2. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин